

/Күренекле шәхесләр/

## Бабабыз хатирәсе

Безнең бабабыз – **Вәлиев Габдрахман Шәйхетдин улы** 1922 елда Тактаны авылында дөньяга килә. Бөек Ватан сугышы башлангач, 1941 елның 28 сентябрендә 19 яшендә мобилизацияләнеп, Ерак Көнчыгышка, 63 чик буе отрядына җибәрелә. Анда – Кытай чигендә бабай 1942 ел башына чаклы хезмәт итә.

1942 елның январенда Габдрахман бабай совет-германия фронтына күчерелә. 162нче укчы дивизиянең 369нче артиллерия полкында минометчы һәм повар булып хезмәт итә башлый. 1942 елның яз һәм җәй айларында 162нче укчы дивизия башта 28нче, аннары 38нче армияләр составында, Харьков шәһәре тирәсендә авыр сугышлар алып бара. Бу сугышлар нәтиҗәсендә бабайлар дивизиясеннән барлыгы 500 солдат кына исән кала.

1942 елның августыннан алып сугыш беткәнчегә чаклы бабабыз 37нче гвардия укчы дивизиясенә кергән 109нчы гвардия укчы полкында минометчы һәм укчы булып хезмәт итә. 1942 ел ахырына кадәр бабайларның дивизиясе 62нче армия составында Сталинград өчен сугышларда катнаша.

1943 елның февраль – октябрь айларында бабайлар 65нче армия составында Үзәк фронтта, ә 1943 елның ноябреннән 1944 февраленәчә Белоруссия фронтында сугышалар. 1943 елның1 ноябрендә Габдрахман бабай үзенең беренче хәрби бүләген – “Батырлык өчен”(«За отвагу») медален ала.

1944 елның мартыннан ноябренә чаклы бабабыз 1нче Белоруссия фронтында була. Белоруссия һәм Польшаны азат итү буенча алып барылган«Багратион» операциясендә катнаша. 1944 елның 25 июлендә Слоним шәһәрен азат итүдә иң беренче булып бәреп кергән өчен икенче “Батырлык өчен” медале белән бүләкләнә. 1944 елның декабреннән 1945 елның маенача бабай 2нче Белоруссия фронтында Төньяк Польша һәм Германиядәге немец гаскәрләрен тар-мар итүдә катнаша. Бабабызның соңгы яулары Берлинны алу өчен барган сугышлар була. Үзенең өченче хәрби бүләге – “Германияне җиңгән өчен”(«За победу над Германией») медален ул Җиңү көнендә – 1945 елның 9 маенда ала.

Гвардия ефрейторы Вәлиев Габдрахман 1945 елның октябрендә демобилизацияләнә. Сугыш елларында ул 4 тапкыр яралана. Авылга кайтканнан соң бабай колхозда бригадир булып эшли башлый. Әби белән өйләнешеп 5 бала тәрбияләп үстерәләр. Эшкә уңган булганлыктан, балта остасы һөнәрен үзләштерә. Фуражир булып та эшли. Актив һәм булдыклылыгына күрә депутаты итеп тә сайлана.




Хәтере яхшы булганлыктан, бабабыз үзенең сугышчан юлындагы һәм шәһәрне, анда булып узган хәлләрне исендә тоткан. Берлин өчен сугышларның аеруча авыр булганлыгы турында сөйли торган булган. Ә без бабай хезмәт иткән гаскәрләр һәм фронтлар турында интернетка чыгарылган документлардан белә алдык. Бу эштә безгә тарих укытучысы Рафик абый ярдәм итте.

Габдрахман бабай озын гомер яшәп, 2014 елны 92 яшендә вафат булды. Без, Габдрахман бабай варислары, аның якты истәлеген саклап, рухына багышлап дога кылабыз.

*Мәрьям һәм Ибраһим Вәлиевлар, VIII сыйныф укучылары*

/ Безнең спорт/




8нче май көнне Норлат районы Чулпан авылында атказанган механизатор Хәбибуллин Сабир истәлегенә багышланган билбау көрәшендә безнең VI сыйныф укучысы **Замалетдинов Зөлфәт** үз авырлыгында II урынны алды. Аны зур җиңүе белән котлыйбыз, алдагы көндә дә уңышлы көрәшләр генә теләп калабыз!

/ Котлыйбыз!/



Ямьле май аенда дөньяга авац салган дусларыбыз **Сафиуллина Кәримәне** (VIIсыйныф), **Вәлиева Мәрьямне** (VIII сыйныф), **Шичкин Алины** (IX сыйныф) туган көннәре белән котлыйбыз. Аларга ныклы сәламәтлек, уңышлар телибез. Әти-әниләренең горурлыклары булыгыз!

Башлангыч сыйныфлар укытучысы **Хәйруллина Рузилә апаны** да гомер бәйрәме белән котлап, ныклы сәламәтлек, иҗади уңышлар теләп калабыз.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Тәхвәтуллин



# Мәктәп хәбәрчесе

**№5**
**(№66)**
**май**
**2025 ел**

Түбән Майна урта мәктәбе газете

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru



/ Мәктәп тормышы/



## Соңгы кыңгырау - саубуллашу авазы

Ел саен бу көн чыгарылыш укучысы өчен балачактан, үсмер чордан аерылу көне. Бүгенге кыңгырау үткәннәргә йомгак, киләчәккә чакыру булып яңгырый. Кыңгырау мәктәп чорында дәрескә чакырса, бүгеннән олы тормышка, хыялларның ак канатларын сынарга өндәп чыңлый.

Әйе, бүгенге чыңлау башка көннәрдәген аерыла шул. Җитди дә, моңсу да, шатлыклы да. Шатлык булмый, ни дисең. Кайчан гына шук булган балалар бүгенге бәйрәм чарасында төп кунаклар. Алар – чыгарылышлар. Соңгы кыңгырау мәктәптә 24нче майда үтте. IX сыйныфның өч, XI сыйныфның ике укучысы бәйрәм түрендә урын алды. Кереш шигырьләреннән соң аларны котлау өчен сүзне директор Насыйров Рафик Гомәр улына бирелде. Ул мәктәпне тәмамлаулары белән котлады. Укучыларга һәрвакыттагыча сынатмаска, куйган максатларга ирешергә, тырышып белем алырга өндәде.

Мәктәпкә район администрациясеннән килгән вәкил Ислямов Илдар Ирек улы да укучыларның һәрберсенә изге теләкләрен җиткереп, туган җирдә эшләргә кайтырга чакырды. Җирле үзидарә башлыгы ярдәмчесе Морадимова Гөлнара да җирле үзидарә исеменнән балаларны котлап, үзенең теләкләрен җиткерде. Мәгариф ветераннары Исмагилов Рафик абый, Хәсәнова Резедә һәм Гафиятуллина Зөлфия апалар да чыгарылышларга сәламәтлек, уңышлар теләделәр. Сыйныф җитәкчеләре дә яраткан укучыларына ихластан тырышып укуларын, хәерле урыннарда эшләргә насыйп булсын дигән теләкләрен җиткерделәр. Әти-әниләр дә балаларына иң изге теләкләрен әйттеләр. Укытучыларга, сыйныф җитәкчеләренә олы рәхмәтләрен белдерделәр.

Укучыларның чыгышы ахырына якынлашкач, иң дулкынландыргыч вакыт җитте. Кыңгырау үзенең көр тавышын моңсуландырып, сагышлардан тасма урләндәй чыңлагач, чыгарылышлар беренче сыйныфка баручы укучыны күтәреп, мәктәп баскычыннан керттеләр. Бу сабыйга тәүге адымнар хәерлесеннән башлансын.

Укучыларыбызга барлык әйтелгән теләкләр кабул булып, һәрберсе үзе өчен дә, җәмгыять өчен дә кирәкле һөнәрен үзләштереп, үзебезнең туган якларга эшкә кайтсыннар иде дигән теләктә калам. Яшәү мәгънәсен кайда да табып була. Туган җирдә бигрәк тә. Бары тик йөрәктә теләк, беләктә көч булып, кече ВАТАНЫБЫЗны сакларга, үстерергә кирәк. Чыгарылыш сыйныф укучыларының үзләре урынына алмаш буын авылда да булырга тиеш.



24 нче май – башлангыч сыйныфлар тәмамланып югары якка күчү вакытын да билгеләде. Рузилә апаларының канаты астында тәрбияләнгән, башлангыч белемне алган 6 укучы киләсе уку елына V сыйныфка киләчәкләр. Алар да апалары белән саубуллашуны зурлап бәйрәм иттеләр. Рузилә апаларының киңәшләрен, алган белемнәрен онытмыйча килерләр дә, тырышып укырлар дигән теләктә калабыз.

*Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир*

/ Мәктәп тормышы/

## Уку елы нәтиҗәләре

Быелгы уку елын 39 укучы тәмамлады. Гомуми белем сыйфаты 71% тәшкил итте. Отличниклар: IIIсыйныфтан **Гафиятуллина Руфинә**; IVсыйныфтан **Закиров Инсаф** белән **Камалов Илнур**;V сыйныфтан **Нурматова Асия**,VII сыйныфтан **Закирова Ләйсән**, VIIIсыйныфтан **Гафиятуллин Фаил.**

Мәктәптән тыш чаралар буенча югары нәтиҗәләргә ирешкән укучылар:

- фән олимпиадаларында –**Нурматова Асия**(Vсыйныф), **Закирова Ләйсән**(VIIсыйныф), **Гафиятуллин Фаил**(VIIIсыйныф); **Гафиятуллин Самат** һәм **Нурматова Зәйнәп** (XI сыйныф);
- спорт юнәлешендә – көрәшчеләр **Замалетдинов Зөлфәт**, **Сәгъдиев Рәмзис** (VIсыйныф), **Шичкин Али** (IXсыйныф), шахматчы – **Гафиятуллин Фаил** (VIIIсыйныф);
- әдәбият һәм сәнгать юнәлешендә – **Закиров Инсаф** (IVсыйныф), **Нурматова Асия** (V сыйныф), **Насыйрова Кәүсәр** белән**Закирова Ләйсән** (VIIсыйныф),**Вәлиев Ибраһим**, **Залиева Вәсилә** (VIIIсыйныф)

**Илдар Сафиуллин, уку-укыту буенча директор урынбасары**



**/ Мәктәп тормышы/**

## Хәтерлибез, горурланабыз!

9нчы май көнне авылыбызда Бөек Җиңүнең 80 еллыгына багышланган тантана узды. Бәйрәм иртәсендә Бөек Ватан сугышында һәлак булган һәм җиңү яулап кайткан авылдашларыбыз хөрмәтенә төзелгән һәйкәл яны сугыш җырларына, хәтирәләргә күмелде. Тантананың иң кадерле кунаклары – сугыш чоры балалары булды, бәйрәмгә шулай ук авылдашлар, кайткан кунаклар килгән иде. Өлкән буынны укучылар үз куллары белән ясалган открыткалар белән котладылар.

Бәйрәмне мәктәбебез укучылары алып барды. Чара, сугыш чоры җырлары, сугыш турында шигырьләр белән үрелеп барды. Соңыннан бәйрәмдә катнашучылар һәлак булган батырларны, җиңүне якынайткан һәм бакыйлыкка күчкән тыл ветераннарын бер минутлык тынлык белән искә алдылар. Һәйкәл итәгенә чәчәк бәйләмнәре салынды.«Үлемсез полк» акциясе – Җиңү бәйрәменең тагын бер күркәм традицияләренә әверелеп бара. Әлеге чарага мәктәп укучылары да, кайткан кунаклар да бик теләп кушылды.

Җиңү көне бездән ерагая барган саен, Ватан азатлыгы өчен сугышларда катнашкан кешеләр дә китә. Безнең авылның соңгы сугыш ветераны инде 2003нче елда ук вафат булды. Инде сугыш чоры балалары да авылда санаулы гына калды. Ләкин халыкның батырлыгы турында хәтер бетми. Ул китапларда, фотографияләрдә, фильмнарда, музей күргәзмәләрендә кала. Безнең һәрберебез, иң беренче чиратта, үз гаиләбез тарихын белергә тиеш. Шуңардан соң әби-бабаларыбызның ил тарихындагы вакыйгаларга керткән өлешен барларга кирәк. Менә шул рәвешле үзебезнең дә зур тарихта эз калдыручылар булуыбызны аңларбыз.

***Зәйнәп Нурматова, XI сыйныф укучысы***

**/ Мәктәп тормышы/**



Башлангыч сыйныф укучылары Яз һәм хезмәт бәйрәме уңаеннан "Бәйрәм атрибуты" кысасында үзләренең иҗади эшчәнлекләрен оештырып җибәрделәр. Шул уңайдан бәйрәм открыткалары, чәчәкләр, плакатлар ясадылар. Укучыларда бәйрәм тарихы аеруча кызыксыну уятты.

Бөек Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан "Батырлар безнең арада" акциясе исеме астында укучылар мәктәп бинасы тәрәзәләрен бизәделәр. Ватан сугышы батырлары турында мәгълүмат туплап стенка урнаштырылды. Кул эшләре ясаучылар да булды. Стенд янында укучылар башкаруында шигырьләр сөйләнде, җырлар яңгырады.



3-8 сыйныф укучылары өчен "Җиңү варислары" дип аталган кино карау дәресе оештырылды. Балалар Бөек Ватан сугышы тарихы белән таныштылар. Фильм балаларга ошады. Алар бурыч, намус, батырлык, патриотлык, җаваплылык, тырышлык кебек темалар буенча фикер алыштылар.

Әти-әниләр белән берлектә "Бөек Җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан укучылар белән нәрсәләр турында сөйләшергә" дигән темага гомуми мәктәп җыелышы үтте. Җыелышның максаты әти-әниләргә укучылар белән эзләнү эшләрен нинди чыганаклардан табарга мөмкинлеге турында белешмә җиткерелде.

18нчы майда 1977 елдан башлап бөтен дөньяда Халыкара музейлар көне билгеләп үтелә. Бу көнне башлангыч сыйныф укучылары әлеге көнгә багышланган презентацияләр карауда катнаштылар. Караганнан соң фикер алыштык, үзебез өчен ниндидер мөһим һәм кирәкле әйбер ачтык. Мәктәп музеенда булдык һәм музейларга йөрү фикерләүне үстерә, дөньяга карашны киңәйтә дигән нәтиҗәгә килдек. Музейларга йөрү хәзерге вакытта авырлык тудырмый, чөнки виртуаль музейлар да эшләнгән.

Язу кешенең фикерен мәңгеләштерде, кешегә аларны кәгазьгә язып бирде. Ел саен 24 май Славян язуы һәм мәдәнияте көне буларак билгеләп үтелә. Әлеге бәйрәм уңаеннан мәктәптә "могҗизалы бүләк мәгърифәтчелек" дигән танып-белү сәгате оештырылды. Чара барышында укучылар бәйрәмнең барлыкка килү тарихы, славян әлифбасын булдыручы, бертуган мәгрифәтьчеләр Кирилл һәм Мефодий белән таныштылар. Чаралар электрон презентация белән үрелеп барды. Татар әлифбасының 1939нчы елдан бирле шушу графикага нигезләнгәнен дә искә төшердек.

***Гөлфия Әхмәтҗанова, тәрбия эшләре буенча киңәшче***

**/ Безнең сәяхәтләр/**



## Язгы табигать кочагында

Безнең мәктәп укучылары кебек сәяхәттән тәм тапкан укучылар бармы икән? Кар эреп яшеллек күренә башлагач, укытучы апа-абыйларны сорап йөдәтә башлыйбыз. Бераз сатулашканнан соң алар бер матур кояшлы көндә авыл тирәсендәге гүзәл бер урынга алып чыгып китәләр. Юлны кем автобуста, кем велосипедта уза. Узыша-ярыша билгеләнгән урында барып та җитәбез. Шул урыннан да матур җир юктыр кебек уйлап кайтабыз да, киләсе елда тагын да матуррагы була.

Быел менә элекке елларда Сабантуй була торган болынга бардык. Монда килгәч тә ниндидер саф, яңа гына баш күтәрә башлаган үлән исе борынга керә. Аяк астында шарт та шорт итеп көздән җәелгән яфраклар сөйләшә, аларны этеп-төртеп яшь үләннәр башларын күтәрә. Кайдадыр якын тирәдә кошлар сайрый. Шунда ук, туган якларын сагынып кайткан кыр үрдәкләренең елга-күл тирәләрендә оя корырга җыенганнарын күзәтәсең. Монда һәр җирдә тормыш кайный. Ерактан кайткан кошлар да, монда кышлаганнары да уздырып-уздырып оя кора, кырмыскалар да кояшта сыртын кыздырып үз эшләре белән мәш килә. Шушы җанлылыкны бераз күзәткәннән соң, алып килгән ризыклар белән тамак ялгап алгач, туп тибәргә керештек. Егетләр учак тергезергә коры агачлар ташышты. Чөнки укытучы апаларыбыз безгә тәмле уха, икенче казанда компот кайнатачаклар. Учак яна башлагач башлангыч сыйныф укучыларына башка төрле эш башлана. Алар учакта төрле ризыклар кыздырып ашый башлыйлар.

Без барыбызда бергәләп футбол уйнадык. Йөгереп арыгач, апаларыбыз безне тәмле аш ашарга чакырды. Казандагы ухага да үзебезнең Чирмешәннән тотылган балык салына. Аны да үзебезнең мәктәп балалары тота инде, елга буенда кармак салырга яратучы егетләр җитәрлек үзебездә. Учакта күмердә пешкән бәрәңгедән дә тәмле ризык юктыр инде ул. Компотын да кибеттәге бер генә сок та алыштыра алмый. Авыл баласының бу рәхәте сүзләргә генә сыя торган түгел. Гомәр абый Бәширов кебек әйтсәк, туган ягым – яшел бишек! Табигать үз баласына ризыгын да, рәхәтен дә, гомумән, барлык мөмкинлекләрен биргән. Безгә укытучыларыбыз табигатьтә уйнатып, аны яратырга да, сокланырга да, иң мөһиме – сакчыл караш та тәрбиялиләр. Кайтыр алдыннан үзебездән калган барлык чүп-чарларны җыештырып та алабыз.

Урманда, болында ял итүне сүзләр белән генә җиткереп бетерә торган түгел. Моны һәр кеше үзе тоярга, үз күзе белән күреп хисләнергә, шул мохитка чумарга тиеш. Шундый гади матурлыкны, аяк астыбызда булган гүзәллекне күрергә өйрәткән апа-абыйларыбызга рәхмәт әйтәсем килә.

***Вәлиев Ибраһим, VIII сыйныф укучысы***

**/ Безнең уңышлар/**




16нчы май көнне Аксубай районының Кривозерка урта мәктәбендә Советлар Союзы герое Г.Г.Романов исеменә һәм Бөек җиңүнең 80 еллыгына багышланган районкүләм фәнни-гамәли конференция булып узды. Чарада безнең укучылар да актив катнашты. VIII сыйныфтан **Залиева Вәсилә** белән **Вәлиев Ибраһим** һәм мәктәпне тәмамлау алдында торган XI сыйныф укучысы **Гафиятуллин Самат** үз чыгышлары белән райондаш укучылар арасында I урынга лаек булды. Самат безнең мәктәптә Бөек Ватан сугышында катнашучыларны барлау буенча алып барыла торган **“Барыбызга уртак бер җиңү”** дигән проект белән таныштырды. Ибраһим белән Вәсилә үз бабалары мисалында проект эчендә нинди эшләр башкарып булганын күрсәттеләр.

Безнең укучылар барысы да сугыш чоры хәрби киемнәреннән һәм корал макетлары белән килгән иде. Шуңардан файдаланып алар конференция катнашучыларга сугыш чоры кораллары турында да мәгълүмат бирделәр. Ә башкаларга алар белән басып селфи ясау мөмкинлеге дә булды.

Мәктәптә уку дәверендә бик күп иҗади бәйгеләрдә катнашкан Самат өчен бу конференция йомгаклау чарасы кебек булды. Укучыларыбызга киләчәктә дә уңышлар теләп калабыз.

Республика Олимпиада үзәге үткәргән чараларда укучыларыбыз актив катнашып баралар. Шуларның соңгысы татар теленнән олимпиада иде. Безнең нәтиҗәләр:**Закиров Инсаф** белән **Камалов Илнур** ( IV сыйныф) – җиңүче исемен алдылар.**Гафиятуллинна Руфинә** (III сыйныф)һәм **Хайруллин Мансур** (II сыйныф) призёр дипломнарына ия булдылар. **Сафиуллина Гөлсем** (IV сыйныф)һәм **Хабибрахманова Асия** (II сыйныф) катнашучы дипломнары белән бүләкләнделәр.Укучыларыбызга алда тагын да зуррак уңышлар телибез.